РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА МАМЫКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Мамык ав.

**КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел

№ 1

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мамык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2025 елның 29 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Тельман ур., 51а йорты адресы буенча «Нефтьче» авыл мәдәният йортында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Тельман, Октябрь, Крупская, Буденный, Яшьләр, Куйбышев, Кызылармия, Ворошилов, Пионер, Елга, Киров ткр., Комсомол тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 30 октябрендә сәгать 16 сәг.00 минутта Мамык авылы Гоголь урамы, 10 йорт адресы буенча Мамык урманчылыгы бинасы янында Мамык авыл җирлеге Мамык авылында Гоголь, Совет, Пушкин, Мичурин, Подлесная, Чапаев урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 31 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Мамык авылының Заречный тыкрыгы буенча 14нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Елга арьягы, Нефтьчеләр, Евгений Грунис, Елга арьягы тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2025 елның 1 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта Мамык авылының Күл яны урамы буенча 5 нче номерлы йорт янында Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлегенең Мамык авылында Подстанция, Күл Яны, Күл Яны

тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Мамык авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ворошилов ур.);
- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (Куйбышев һәм Приозерная урамнарында авария хәлендәге иске агачларны кисү; Ворошилов, Куйбышев урамнарындагы җәяүлеләр басмасын ремонтлау).

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков